СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район,
село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы,
Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы,
73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 22 нче сентябре № 33-117

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегенең генераль планын әзерләү зарурлыгы турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмаганга күрә, комплексłы социаль-икътисадый үсешнең расланган программасы юк һәм Татарстан Республикасы һәм Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары белән федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган булу нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның «31» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегенең генераль планын эшләү кирәк түгеллеген танырга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 25.08.2023 №32-114 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 28.02.2022 № 18-58 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Тубылгытау авыл җирлеге генераль планын әзерләү кирәк булмау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның «01» сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмәгыйлев